**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

от 08.02.2021ел №07-04

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294 - ФЗ номерлы Федераль закон «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» ? нигезендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга (1нче кушымта).
2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре һәм башкарма комитет органнары исемлеген алып баруны йөкләргә.
3. Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары һәм муниципаль контроль төрләре исемлеге турында» 2019 елның 16 декабрендәге 43-08 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә игълан итәргә.

Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе Э.Н.Фәттахов

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районы Советы карарына
08. 02.2021 ел №07-04
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре исемлеге

| т/б | Муниципаль контроль төре | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруны регламентлаучы норматив хокукый актлар (конкрет нигезләмә, статья, пункт, абзацларны күрсәтеп, реквизитларны да кертеп) | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (структур бүлекчәләр) |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль җир контроле | Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, 1 өлеше, 26 пункты | Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |